**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЯШЬЛӘР ЭШЛӘРЕ ҺӘМ СПОРТ МИНИСТРЛЫГЫ**

БОЕРЫК

24.06.2015 Казан № 352

Татарстан Республикасы Яшьләр эшләре, спорт һәм туризм министрлыгы боерыкларының үз көчен югалткан дип тану турында

Татарстан Республикасы Президентының 2014 елның 3 мартында кул куелган УП-235 номерлы «Татарстан Республикасының Туризм агентлыгы турында» Указы нигезендә

боерам:

1. Үз көчен югалткан дип танырга:

Татарстан Республикасы Яшьләр эшләре, спорт һәм туризм министрлыгының 2012 елның 2 апрелендә кул куелган 226 номерлы «Кунакханәләр һәм урнаштыру өчен башка төр чараларны, таудан чаңгы шуу трассаларын, комлыкларны үз эченә алган туристлык индустриясе объектларын классификацияләүне тормышка ашыра торган оешмаларны аккредитацияләү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентын раслау турында» боерыгын;

Татарстан Республикасы Яшьләр эшләре, спорт һәм туризм министрлыгының 2012 елның 2 апрелендә кул куелган 226 номерлы «Кунакханәләр һәм урнаштыру өчен башка төр чараларны, таудан чаңгы шуу трассаларын, комлыкларны үз эченә алган туристлык индустриясе объектларын классификацияләүне тормышка ашыра торган оешмаларны аккредитацияләү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентын раслау турында» боерыгы тарафыннан расланган Татарстан Республикасы Яшьләр эшләре, спорт һәм туризм министрлыгының 2013 елның 3 июнендә кабул ителгән 431 номерлы «Кунакханәләр һәм урнаштыру өчен башка төр чараларны, таудан чаңгы шуу трассаларын, комлыкларны үз

эченә алган туристлык индустриясе объектларын классификацияләүне тормышка ашыра торган оешмаларны аккредитацияләү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентына үзгәрешләр кертү турында» боерыгын.

2. Юридик эшләр секторына (О.Б.Вощакина) әлеге боерыкны дәүләт теркәве уздыру өчен Татарстан Республикасы Юстиция министрлыгына юлларга.

3. Әлеге боерыкның үтәлешен тикшерүне министрның беренче урынбасары Х.Х.Шәйхетдиновка йөкләргә.

Министр В.А.Леонов